| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**Об отмене ограничительных мероприятий (карантина), установленных на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения**

В связи с выполнением противоэпизоотических и профилактических мероприятий по ликвидации и предотвращению заболевания высокопатогенным гриппом птиц, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии», приказом Министерства сельского хозяйства Российской Федерации от 24 марта 2021 года № 158 «Об утверждении Ветеринарных правил осуществления профилактических, диагностических, ограничительных и иных мероприятий, установления и отмены карантина и иных ограничений, направленных на предотвращение распространения и ликвидацию очагов высокопатогенного гриппа птиц» **постановляю:**

1. Отменить ограничительные мероприятия (карантин) по высокопатогенному гриппу птиц на следующих отдельных территориях Республики Татарстан:

а) в эпизоотических очагах:

территория крестьянского (фермерского) хозяйства «Латипов Нияз Рафаилович» в Дым-Тамакском сельском поселении муниципального образования «Ютазинский муниципальный район Республики Татарстан» радиусом 200 м от географических координат: 54,530949° северной широты и 53,354518° восточной долготы;

территория личного подсобного хозяйства в Дым-Тамакском сельском поселении муниципального образования «Ютазинский муниципальный район Республики Татарстан» радиусом 100 м от географических координат 54,527806° северной широты и 53,371532° восточной долготы;

б) в угрожаемой зоне в пределах территории радиусом 5 км от границ эпизоотических очагов, включая село Дым-Тамак, поселок Екатериновка, деревню Алабакуль, деревню Тарлау, поселок железнодорожного разъезда Абсалямово, село Абсалямово Ютазинского района, деревню Уба Бавлинского района Республики Татарстан.

2. Ограничить на территориях, указанных в пункте 1 настоящего Указа, в течение 90 календарных дней со дня отмены карантина (за исключением птицефабрик, расположенных на территории угрожаемой зоны) вывоз птиц и инкубационного яйца.

3. Признать утратившим силу Указ Раиса Республики Татарстан от 4 ноября 2025 года № 910 «Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельных территориях Республики Татарстан в связи с их неблагополучием по заболеванию высокопатогенным гриппом птиц и угрозой его распространения».

4. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** **Р.Н. Минниханов**

Казань, Кремль
18 декабря 2025 года
№ 1050

| | | |
|---|---|---|
| **УКАЗ**<br>РАИСА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>РӘИСЕ<br>**УКАЗЫ** |

**Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Кошларның йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләвен бетерү һәм булдырмауга юнәлтелгән эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар үтәлүгә бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы, Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгының «Йогышлылыгы югары булган кош гриппы таралуын һәм аның чыганакларын бетерүгә юнәлтелгән карантин һәм башка чикләүләр кертү һәм аларны бетерү буенча профилактика, диагностика, чикләү һәм башка чараларны тормышка ашыру буенча ветеринария кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 24 мартындагы 158 номерлы боерыгы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасының түбәндәге аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы буенча чикләү чараларын (карантинны) бетерергә:

а) эпизоотия чыганакларында:

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Димтамак авыл җирлегендәге «Латыйпов Нияз Рафаил улы» крестьян (фермер) хуҗалыгының төньяк киңлекнең 54,530949° һәм көнчыгыш озынлыкның 53,354518° географик координатларыннан 200 м радиустагы территориясендә;

«Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Димтамак авыл җирлегендәге шәхси йорт хуҗалыгының төньяк киңлекнең 54,527806° һәм көнчыгыш озынлыкның 53,371532° географик координатларыннан 100 м радиустагы территориясендә;

б) эпизоотия чыганагыннан 5 км радиустагы территория чикләрендә, Татарстан Республикасы Ютазы районының Димтамак авылын, Екатериновка поселогын, Алабакүл авылын, Тарлау авылын, Әбсәләм тимер юл разъезды поселогын, Әбсәләм авылын, Баулы районының Уба авылын кертеп, куркыныч янау зонасында;

2. Әлеге Указның 1 пунктында күрсәтелгән территорияләрдә (куркыныч янау зонасы территориясендә урнашкан кошчылык фабрикаларыннан тыш) карантин бетерелгән көннән соң 90 календарь көн дәвамында кош-кортларны һәм яралгылы йомырка чыгаруны чикләргә.

3. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы һәм аның таралу куркынычы белән бәйле рәвештә, аларның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2025 елның 4 ноябрендәге 910 номерлы Указын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2025 ел, 18 декабрь
№ 1050